**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Кариле авыл җирлегенең Олы Кариле авылында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**05 декабрь 2024 ел** **№5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авыл җирлеге Олы Кариле авылында гражданнарның җыены карар итте**:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Кариле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы;

-су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау;

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Кариле авылы, Пионер ур., 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Чаллы авылы, Ленин ур., 43;

-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Кариле авылы, Вахитов ур., 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып

чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Олы Кариле
авыл җирлеге башлыгы: Ф.Г.Гарифуллин